Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# UNIVERSITET
УНИВЕРСИТЕТ

№ 5 (18)

23 февраль 2012 ел

## • Ике авыз сүз

20 февраль көнне фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев җитәкчелегендә КФУның чираттагы Гыйльми совет утырышы узды. Бередә түбәндәге мәсьәләләр каралды: биология һәм туфракны өйрәнү факультеты һәм аның үсеш перспективалары; 2011 елда Үсеш программасының үтәлеш нәтиҗәсе һәм 2012 елга планнар; кафедра мөдирләрен сайлау; гыйльми дәрәҗәгә тәкъдим итү; 2012 елга мәгариф өлкәсендә РФ бүләгенә тәкъдим итү; төрлеләр.

Беренче сорау буенча, факультетның бүгенге хәле, алга таба үсеш перспективалары турында декан Рушан Сабиров чыгыш ясады. Ул бай тарихы булган әлеге факультетта бөтен дөньяга танылган биология мәктәпләренең хәзер дә элеккеге традицияләре саклануына, үсешеяңарышына басым ясады. Факультетта бүгенге көндә эшләп килгән бүлекләргә өстәп, биотехнология, су биоресурслары һәм аквакультура кебек яңа юнәлешләр ачылачагы турында да хәбәр итте. Гомуми физика кафедрасы профессоры Александр Фишман әлеге факультетның 2010-2011 уку елындагы эшчәнлеге турында сөйләде. Фикер алышу вакытында иң зур игътибар Ботаника бакчасы язмышына юнәлдерелде. Рушан Сабиров әлеге бакчаның күпмедер өлешеннән баш тартырга кирәклеге турында әйтсә дә, Гыйльми совет әгъзалары тарафыннан аны саклап калырга, үсеш концепциясен төзергә кирәклеге искәртелде.

Традицион рәвештә, КФУның Үсеш программасы турында икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин чыгыш ясады. Ул бәяләп узганча, 2011 елгы күрсәткечләр университетның алга куелган планнарны хәтта арттырып үтәве турында сөйли, программа 140% ка үтәлгән. Бу планда каралганнан ике тапкырга артык дигән сүз. Мәсәлән, электрон белем бирү ресурслары (248 гә 60) планлаштырылганнан икеләтә арттырып эшләнгән, аспирантлар саны арткан, өстәмә белем бирү программалары да сан ягыннан шактый зур үсеш кичергән. Узган ел эчендә 25 кече инновацион предприятие (планда каралганнан 14 кә күбрәк) булдырылган. Шулай ук Татарстан Республикасыннан булмаган студентларның, югары уку йортыбызда белем һәм тәрбия бирүче чит ил галимнәренең артуы да күңелле күренеш. Биналар мәйданы – 281% ка (224 тән алып 630 га кадәр), җир мәйданы 123% ка (294,2 дән 362,44 кә кадәр) арткан.

Алга таба кафедра мөдирләрен сайлау, гыйльми дәрәҗәгә һәм 2012 елга мәгариф өлкәсендә РФ бүләгенә тәкъдим итү буенча фикер алышу булды.

• • • •

13-14 апрель көннәрендә Казан федераль университетының Алабуга филиалында «Яңа буын укытучысы» бәйгесе узачак. Катнашу өчен Идел буе федераль округыннан педагогик югары уку йортларында белем алучы студентлар командалары чакырыла. Педагогикага бәйле актуаль мәсьәләләр мастер-класслар, кызыклы шәхесләр белән очрашулар, мәдәни-күңел ачу чаралары, Алабуга шәһәре буйлап сәяхәт барышында хәл ителәчәк.

«Яңа буын укытучысы» – яңартылган мәгариф системасында көндәшлеккә сәләтле яшь белгечләр әзерләүгә булышлык итә торган проектларның берсе. Тәүге тапкыр ул 2010 елда уза. Ул вакытта Алабуга дәүләт педагогика университетының барлык факультетларында белем алучы студентлар катнаша. Психологик тренинглардан тыш, проектта катнашучыларны әзерләү программасына һөнәри эшчәнлектә инглиз теле, педагогик инновация һәм педагогик культура кебек курслар да керә.

Бередә катнашу тәртибе һәм таләпләр белән сез университетның рәсми сайтында таныша аласыз.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




Алина Хангәрәева фотосы

# Намус һәм дан өчен!

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

21 февраль көнне Казан федераль университеты галим-мөгаллимнәре, студентлары Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтте. Аның төп оештыручылары спортчылар иде, ягъни университетыбызның Физик тәрбия һәм терәкләндерү медицинасы институты. Алар быел аны Филология һәм сәнгать институты белән берлектә уткәрде.

Чарада университетның социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректоры Ариф Межведилов, мактаулы кунаклардан генерал-майор, университетыбызның куркынычсызлык һәм тормыш иминлеге кафедрасы мөдире Рим Мостаев, ветераннарыбыз, хәрби оркестр һәм танк училищесы курсантлары катнашты. Төп максат, әлбәттә, яшьләрне сәламәт яшәү рәвешенә өндәү һәм ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү иде.

Ариф Межведилов үз чыгышында әлеге матур чарага заманында ТДГПУ коллективы нигез салуын билгеләп үтте һәм: «Алга таба әлеге традицияне университет күләмендә тагын да җәелдерербез. Яшьләрнең үз Ватаннарын ничек яратуын дәлилләгән ветераннарыбыз белән күзгә-күз очрашуы – бәһасез», – дип белдерде.

Шулай ук тәбрикләү сүзләрен Әфганчы ветераннарының Россия Союзы республика бүлеге рәисе, ТРның Иҗтимагый палатасы әгъзасы Евгений Камышев һәм Әфган сугышы инвалидларының республика иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Альберт Кухаркин да җиткерде.

Чарада ике институтның директорлары Рәдиф Җамалетдинов һәм Искәндәр Галиев Гомумроссия Әфган сугышы инвалидлары иҗтимагый оешмасының «Намус һәм дан» медале белән бүләкләнде. Физик тәрбия һәм терәкләндерү медицинасы институты, Филология һәм сәнгать институты студентлары тарафыннан әзерләнгән концерт номерлары да тамашачылар күңеленә хуш килде.

**Теманың дәвамы 4 нче биттә**

## • Сезне бездә көтәләр

# Абитуриентның үз көне бар!

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Казан федераль университеты 26 февраль көнне Ачык ишекләр көне уздыра. Аерым институт-факультетлар үзләре дә булачак студентларын барлау белән даими шөгыльләнеп киләләр.

Шундый чараларның берсе 19 февраль көнне Филология һәм сәнгать институтында узды. Ул Абитуриент көне дип аталды. Бу көнне институт үзенең ишекләрен бары абитуриентлар өчен генә ачты. Институтның һәр бүлеге бу көнне булачак студентлары белән очрашты. Әлегә мәктәп укучылары булган абитуриентларны, аларның укытучыларын һәм әти-әниләрен роман-герман филологиясе, рус филологиясе, татар филологиясе, сәнгать, тәрҗемәчелек һәм мәдәниятара багланышлар бүлекләре үз эшчәнлекләре белән якыннан таныштырды.

**Ахыры 2нче биттә.**



Ленар Мөхәммәтшин фотосы

● Сайлаулар – 2012

# Күңелле үзгәрешләр көтә

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

22 февраль көнне университетка ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев һәм ТРның Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева килде. Алар төрле бүлекләрдә белем алучы студентлар белән очрашты.



Ленар Мөхәммәтшин фотосы

Мин катнашкан очрашу узасы залда алма төшәр урын да калмаган иде. «Милләтебезнең киләчәге һәм каймагы – сез», – дип сүзен башлады Разил Исмәгыйль улы. – «Без бүген ике бәйрәм уртасында – Туган тел һәм Ватанны саклаучылар көннәре арасында. Икесе дә бер-берсенә шул дәрәҗәдә бәйләнешле. Ватанны саклау ул – халкыңның йола-гадәтләрен, милли мәгарифеңне, телеңне, гаиләңне дә саклау әле ул».

Кичә барышында студентлар һәм укытучылар килгән кунакка нинди генә сораулар белән мөрәҗәгать итмәде. Бүгенге көндә телебезгә, яшьләр әдәбиятына, мәгариф проблемаларына, хәзерге сәясәт һәм, әлбәттә, тиздән булачак сайлаулар һ.б. бәйле шундый сорауларга тулы, гади җаваплардан бик риза булды тамашачы. «Кеше гомере буе сайлый: башта дусларны, сөйгән ярны, яратып эшләрлек һөнәрне... тыныч, рәхәт яшәүне булдырырлык ил башлыгын. Мондый катлаулы хәлләр алдында беребезгә дә битараф булырга ярамый. Март аенда узачак Президент сайлауларына бик җитди карарга кирәк. Кандидатлар бишәү. Шулар арасында иң кулае – В.В.Путин. 1-2 атна элек аның «Милли мәсьәләләр» дигән мәкаләсен күбегез укыгансыздыр. Тәкъдимнәре арасында киләчәктә субъект җитәкчесен халык үзе сайларга тиеш булачагы; милли эшләр буенча аерым бер дәүләт органы булырга тиешлеге (алай булса, милли мәсьәлә шактый гына хәл ителәчәк); югары уку йортларында укытучыларның хезмәт хакы артачагы; студентларның да стипендиясе арту кебекләре бар. Шушы хәлләрдән соң, Путинга карата күңелем җеби башлады. Ил белән эшләрлек тик ул гынадыр дип уйлыйм», – диде ул сүзен йомгаклап.

● Сезне бездә көтәләр

# Абитуриентның үз көне бар!

**Башы 1нче биттә.**

Татар филологиясе бүлеге вәкилләре, Абитуриент көне белән беррәттән, «Мин туган телемдә сөйләшәм» иҗади бәйгесенә нәтиҗә ясады. Гомуми урта мәктәпләрнең 9-11 сыйныф укучылары, махсус урта белем бирү йортларында белем алучылар өчен оештырылган әлеге бәйгегә Татарстанның шәһәр, авыл мәктәпләреннән, чит өлкәләрдән 335 эш кабул ителгән. Әлеге ике чараның бергә үткәрелүе очраклы түгел, чөнки иншаларның күбесендә укучылар киләчәкләрен татар филологиясе белән бәйләргә теләкләре барлыгын белдергәннәр. Бүлекнең иң күп абитуриент җыюының сере дә шуның белән бәйле иде.

Бу көнне барлык кунаклар Актлар залында җыйналды. Биредә алар ФСИ директоры Рәдиф Җамалетдинов, татар филологиясе бүлеге мөдире Флёра Сәйфуллинаның тәбрикләү-сәламләү сүзләрен, күп кенә галимнәр, бүлекне тәмамлаган язучы-шагыйрьләребез, җәмәгать эшлеклеләренең котлауларын ишетә, төрле конкурс-фестивальләрдә җиңгән студентларның концерт программасын тамаша кыла алды. Зал тутырып килгән укучылар татар филологиясе бүлегенең киләчәге турында сөйли, миңа калса.

● Биологларда кунакта

# Беренче нано адымнар

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Бүген сүзем фәнни эшләре, ачышлары белән Татарстан, Россиядә генә түгел, ә чит илләрдә дә танылган лаборатория хакында. Әле күпләрегез аның турында хәбәрдар түгелдер. Әгәр шулай икән, рәхим итегез: бүген без био һәм наноматериаллар лабораториясендә кунакта.

Лаборатория университетыбызның биология һәм туфракны өйрәнү факультетының берничә кафедрасы белән хезмәттәшлек итә. Аның эшчәнлеген биология, химия яки физика өлкәсе белән генә чикләү һич дөреслеккә туры килмәс. Ачышлар шушы фәннәрнең үзара бәйләнеш нокталарында башкарыла.

«Биредә без наноматериалларны өйрәнү һәм аларны практикада куллану юлларын эзләү белән шөгыльләнәбез. Төп юнәлешебез тере күзәнәкләрне наноматериаллар белән модификацияләүгә юнәлдерелгән. Без бер һәм күпкүзәнәкле төрле организмнар белән, шулай ук кеше күзәнәкләре белән эш итәбез. Тикшеренүләр вакытында әлеге организмнарны, аларга төрле файдалы үзлек бирү максатыннан, магнитлы, алтын, көмеш һ.б. төрле нанокисәкчекләр белән каплыйбыз. Мәсәлән, безнең соңгы эшебезнең максаты: кешенең тере күзәнәкләреннән һәм магнитлы нанокисәкчекләрдән торган гибрид система уйлап табу», – ди микробиология кафедрасының өлкән укытучысы Равил Фәрит улы Фәхруллин. Ул лабораториядә алып барыла торган эзләнүләр, тәҗрибәләр турында сөйләде, киләчәккә планнары белән таныштырды. Хәзерге көндә лабораториядә гибрид күзәнәкләрнең яшәүгә сәләтлелеген, магнит ярдәмендә бер урыннан икенче урынга күчерү мөмкинлекләрен өйрәнәләр. Бу алгарышлы юнәлештә беренче адымнар гына ясала әле. Киләчәктә сәламәт күзәнәкне алып, авыру кешенең зарарланган органына күчерү, ягъни күзәнәк терапиясе өлкәсендә зур ачышлар күздә тотыла.

Лабораториянең икенче тикшеренү өлкәсе – күпкүзәнәкле ясалма система булдыру. Р.Фәхруллин әйтүенчә, фәндә бер күзәнәктән күпкүзәнәкле система барлыкка китерү турында материаллар күп түгел. Бу процесс бик күп еллар элек башланган. Шуңа да аның ни рәвешле баруын төгәл генә аңлату мөмкин түгел. Әлеге күренешне аңлатырга омтылып караган төрле теорияләр бар. Лабораториядә исә үзләренең теорияләрен тәкъдим итәргә җыеналар.

Биредә миңа басылган фәнни хезмәтләр күрсәттеләр. Алар арасында инглиз телендәгеләре өстенлек итүенә гаҗәпләндем. «Эшләребезнең 70% инглиз телендә язылган. Гомумән, бөтен дөньяда фән теле буларак инглиз теле кабул ителгән. Чит илләрдә конференцияләр, очрашулар шул телдә үтә. Фәндәге күпчелек терминнар инглиз телендә. Бу телне камил дәрәҗәдә белмичә, фәндә уңышка ирешеп булмый», – ди лаборатория хезмәткәрләре.


«Иң куандырганы: безнең эшләр Бөекбритания Корольлегенең Химик җәмгыятендә уңай бәяләнде. 2011 елда лабораториянең бер эше Америка Химик җәмгыятендә билгеләп үтелде. Бирегә күп тикшерүләр, сайлап алулар аша гына үтеп була. Безгә кадәр Россия галимнәре бу җәмгыять игътибарына 90 нчы елларда лаек булганнар. Аларның эше Менделеев таблицасында яңа элемент ачу белән бәйле булган. Ә безнең лабораториянең бер ел эчендә ике эше әлеге абруйлы җәмгыятьтә каралды», – дип хаклы рәвештә горурланалар лаборатория хезмәткәрләре.

Тәҗрибә рәвешендә башланган федераль уку йортлары оештыру программасы булдырылганга дистә ел узган. Хәтерләсәгез, әле узган ел гына лаборатория заманча таләпләргә туры китереп җиһазландырылды. Күрәбез, инде бу үз нәтиҗәләрен дә бирә. Совет заманыннан калган җиһазлар күптән яңартылырга тиеш иде. Ниһаять, мәгариф системасына бәйле сәясәт үзгәреп, илебездә федераль университетлар барлыкка килгәч, аларның өстенлекле үсеш программалары булдырылгач, алга китеш сизелә. Максатчан финанслау нәтиҗәсендә университет инфраструктурасы дөнья стандартларына туры килә, заманча таләпләргә җавап бирә. Әлеге үсеш тотрыклы рәвештә дәвам итүендә шик юк.

Бөекбританиядәге Халл университетының нанотехнология белгечләре дә Казан университеты тикшеренүчеләренең эшен бик югары бәяли һәм аларның методикасының фән өлкәсендә бик мөһим, кирәкле адым булуын билгеләп үтә. Әлеге хезмәтләр Корольлекнең Химик җәмгыяте «Soft Matter» журналында да басылган.

«Фән теле инглиз теле булса да, татар телен фән өлкәсендә файдалануда да алга китеш бар. Хәзерге вакытта бу юнәлештә ныклы адымнар белән яңа бер этапка кердек дип әйтер идем», – ди Равил Фәхруллин. – «Фән күзлегеннән караганда, ул үсеш чоры кичерә. Аның киләчәге дә уңышлы булыр. Без дә берничә ел татар филологиясе бүлеге белән берлектә терминнарны татарчага тәрҗемә итү юнәлешендә эшлибез. Мәсәлән, фәндә «динамика» дигән термин яшәп килә. Ул башка телләрдә дә шулай. Татарчага тәрҗемә иткәндә, аның «движение» дигән синонимын кулланырга була. Шулай итеп, татар телендә әлеге өлкәгә кагылышлы «хәрәкәт» дигән билгеләмә барлыкка килә дигән сүз».







### *Яшьләр килә фәнгә... Син дә кил, әйдә!*

Билгеле булганча, һәр өлкәдә үз эшенә чын күңелдән бирелеп, бер йодрык булып тупланган коллектив кына зур уңышларга ирешә ала. Хәзерге вакытта лабораториядә Идел буе төбәгеннән (Татарстан, Мари Эл республикалары, Киров өлкәсе) һәм Вьетнамнан килгән студентлар эшли. Араларында шактый уңышларга ирешкәннәре дә бар. Рената Минуллина – «Ел студенты» булып танылган, Мария Дзамукова – ТР Фәннәр Академиясе стипендиясенә, Светлана Коннова һәм Илзия Шәрипова Казан мэры стипендиясенә лаек булган. Студентлар фәннең нанотехнологияләр кебек катлаулы өлкәсенә ничек килеп керә соң? Шул соравыма җавап табу максатыннан, эш белән кайнаган студентларның берсенә мөрәҗәгать иттем. Ул – шәһәр мэры стипендиясе иясе, Бөтенроссия фән конкурсларының җиңүчесе, биология һәм туфракны өйрәнү факультетының V курс студенты Илзия Шәрипова. Кызның яхшы укуын, әлеге өлкә белән кызыксынуын күреп, Равил әфәнде аны лабораториягә чакырып алган. Илзия монда II курстан бирле эшли икән. Үзе үткәргән тәҗрибәләр нигезендә ике курс эше яклаган, мәкаләләре чит ил журналларында да басылып чыккан. Хәзер диплом яза. «Эшебез күп һәм авыр булса да, барысына да өлгерәм, чөнки миңа биредә һәрвакыт ярдәм итеп, юл күрсәтеп торалар, алга таба да эшләргә юнәлеш бирәләр», – ди Илзия, үзенең остазларына рәхмәтен белдереп. «Эшләр өчен бөтен мөмкинлекләр, уңайлыклар тудырылган, иң мөһиме: теләк һәм максатчанлык кирәк».

«Химия, биология белән кызыксынучы, үзләрен фәнгә багышларга теләгән студентларны көтеп калабыз. Мәктәптә нинди телдә генә белем алса да, лаборатория ишекләре һәркемгә ачык. Без аларга ярдәм кулын сузарга һәрвакыт әзер», – ди Р.Фәрхуллин.

Лаборатория белән якыннан танышкач, шуңа инандым: биредә дөньякүләм әһәмияткә ия фән белән шөгыльләнәләр, аларның тагын да югарырак үрләр яулавына шик-шөбһә юк.

• Галимнәребез

Гомерен математикага, укучылар, студентларга белем бирүгә багышлаган галимә, КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты математиканы һәм информатиканы укыту методикалары һәм технологияләре кафедрасы мөдире Кадрия Бари кызы ШАКИРОВАның юбилее булып үтте. Шул уңайдан без аның белән әңгәмә кордык. Галимәнең тавышыннан ук нур бөркелә, һәр фикере төпле, уйланылган...

# «Көнем мәсьәлә чишүдән башлана»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче



***– Кадрия Бариевна, Сез – бүгенге көндә зур хөрмәткә лаеклы, үз эшенең остасы булган мөгаллим. Моның өчен нинди баскычлар үтәргә туры килде?***

– Мин үзем Казанда туып-үстем. Математик юнәлештәге мәктәпне тәмамлаганнан соң, әтием теләге буенча 1969 елда КДПУның физика-математика факультетына укырга кердем. 1973 елны университетны кызыл дипломга тәмамлаганнан соң, 48 нче мәктәптә укытучы булып эшли башладым. 1975 елда укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары вазифасын үтәдем. Ә 1981 елдан – КДПУның педагогика кафедрасында ассистент, аспирантурага укырга кердем. Кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң, 1995 елдан бирле кафедрабызның җитәкчесе.

***– Мәктәптә укыганда, математика белән кызыксына башлаган идегезме?***

– Математика минем иң яраткан предметларның берсе иде. Юкка гына математика – фәннәр патшасы, дип әйтмәгәннәр бит! Шуңа карамастан, математика укытучысы булырмын дип һич күз алдыма китермәдем. Бу юнәлештән китүемә, мөгаен, математика укытучыбыз һәм әтием сәбәпче булгандыр.

***– Математиканы Сез су урынына эчәсез. Ә бүген Сезнең өчен мәктәп предметларының кайсысы авырлык тудырыр иде?***

– Кызык сорау. Мәктәптә укуны бик ярата идем, барлык фәннәрне дә төбенә төшеп өйрәнеп бардым. Аллага шөкер, бүген дә ул белемнәрне кулланам, барысы да ничектер җиңел сыман тоела! Бары инглиз телен белмәвемне генә зур кимчелегем дип уйлыйм.

***– Кадрия Бариевна, математикның көне нидән башлана?***

– Яшермим, күп көннәр, иртәнге дүрттә торып, мәсьәлә чишүдән башланырга мөмкин. Кичтән җавап таба алмаган мәсьәләгә иртән тотынсаң, барысы да җиңел килеп чыга!

***– Гаиләгез белән дә таныштырып үтсәгез иде.***

– Тормыш иптәшем белән өч бала тәрбияләп үстердек. Улыбыз – КДПУның география факультетын, олы кызыбыз шул ук университетта математика факультетын тәмамлады. Ә кече кызыбыз әле КФУның чит телләр бүлегендә V курста белем ала.

3 оныгыбыз-куанычыбыз бар. Аллага шөкер, гаиләм белән горурлана алам!

***– Сез – күп студентларның яраткан укытучысы. Үзегез ничек уйлыйсыз: педагог буларак, Сез нииндирәк икән?***

– Кызык сорау... Дөресен әйткәндә, мин артык таләпчән түгел. Укыта торган предметым – методика. Ул фәннең асылына хәтта берничә еллар укытканнан соң гына да төшенергә мөмкин. Студент белем алырга тели икән, сине тыңлый, кирәкле материалны эләктереп барырга тырыша. Фәнгә кызыксынуы юк икән, әллә нинди юллар белән дә предметны өйрәнергә мәҗбүр итеп булмый.

***– Бүген математиканы өйрәнү кайсы яклап әһәмиятле дип уйлыйсыз?***

–Уйлап карасаң, математика фәнендә тормышта бер дә кирәге чыкмаслык теоремалар, формулалар шактый. Ләкин алар безнең фикерләү сәләтебезне, баш мие эшчәнлеген яхшырта. Юкка гына күп эшмәкәрләр, сәясәтчеләр нәкъ менә математиклар арасыннан чыкмый бит!

***– Тагын бер актуаль мәсьәлә: БДИ га карашыгыз нинди?***

– Бу идеягә карашым уңай. Бары тик баланы БДИ нәтиҗәләренә карап кына бәяләү, миңа калса, дөрес түгел. Кайбер баланың сәләте математикага булса, икенчесенең географиягә яки биологиягә булырга мөмкин. Тагын шунысын әйтәсем килә: укучыларның имтихан нәтиҗәләре тискәре булган очракта, бар гаепне укытучыга ташлап калдырырга ярамый. Әйткәнемчә, һәр кеше уникаль, мөмкинлекләребез дә төрле.

***– Бүгенге көндә нинди уй-хыяллар белән яшисез?***

– Ходайга шөкер, барыйм дисәм, яраткан эшем бар, өйдә яраткан гаиләм көтә! 60 тан соң әле тормыш гаҗәеп ишекләрен ача гына башлый икән! Янда – балалар, оныклар үсә, үзеңә күп вакыт сарыф итеп була... Һәрнәрсәгә оптимистик караш булдырырга кирәк! Ә минем калган гомеремне дә истәлекләргә, балаларыбызның уңышларына сөенеп, тыныч-имин үткәрәсем килә!

• 21 февраль - Туган тел көне

# «Әткәм-әнкәмнең теле...»

**Рамил ХАННАНОВ**

Казан федераль университетында нинди генә милләт вәкилләре белем алмый. Аларның һәрберсенең үз туган теле бар – кадерле һәм якын.

Уку йортыбызда студентлар 12 телдә белем ала. Татар, рус, инглиз, немец, француз, испан, гарәп, фарсы, төрек, кытай, япон һәм корея телен өйрәнүче күпме яшь белгеч гыйлем туплый. Галим-мөгаллимнәр фикеренчә, әле тагын студентлар өчен берничә тел өйрәнергә мөмкинлекләр ачылачак.

«Башыңа төшсә, кытайча да өйрәнерсең», ди халык. Моңа бездә тулы мөмкинлекләр бар. 2007 елдан бирле Казан университетының Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты каршында эшләп килгән Конфуций институты турында ишеткәч, гаҗәпкә калган идем. Инде кытай теле халыкара тел дәрәҗәсенә дәгъва кылган бу заманда, юкса, хәйран калыр урын да юк кебек...

Туган тел көне бездә ничек билгеләп үтелде соң? Әлбәттә, милләтпәрвәрләр бу датаны игътибар үзәгенә алды. Мәсәлән, 17-18 февраль көннәрендә университетта «Германистиканың бүгенге торышы: заманчалык һәм үсеш перспективалары» дип аталган I Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция узган иде. Нәкъ Туган телебез көнендә «Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар» исеме астында III Республика фәнни-гамәли конференциясе булды. Бирегә Татарстаннан гына түгел, Башкортстан, Пермь кебек чит төбәкләрдән килүчеләр дә бар иде. Конференция кысаларында «түгәрәк өстәл»ләр, мастер-класслар, тренинглар узды, туган телебез сагында торучы мөгаллимнәр үзара киңәш-табыш итте.



Ленар Мөхәммәтшин фотосы

Туган телебез буенча укучыларга белем бирүче мөгаллимнәр бу арада Казанга бик еш киләләр. Сәбәбе - филология һәм сәнгать институтында узган «Абитуриент көне», алда телгә алынган конференция, әле озакламый узачак «Илһамлы каләм» конкурсы һ.б. Әйтергә кирәк, әлеге очрашулар эзсез узмый. Без үз республикабызда гына түгел, чит төбәкләрдә дә милләтебез файдасына нидер үзгәртә алабыз. Сезнең игътибарга Башкортстанның Бишбүләк районыннан килгән бер хат тәкъдим итәм. Аны укыгач, Идел буенда урнашкан ике зур төбәк арасындагы мәсьәләләр хакында да уйланырга була.

***Хөрмәтле Рамил әфәнде!***

*Алсу (Бишбүләкнең рус телендә белем бирелә торган 2 нче мәктәбе укучысы Алсу Вахитова турында сүз бара – ред.) Сезнең университет оештырган «Илһамлы каләм»дә икенче тапкыр катнаша. Уңышларына сөенерлек: конкурс нәтиҗәләре аңа Илдар Гыймаев исемендәге стипендия лауреаты булырга ярдәм итте, «Өмет» газетасы «Чаткылар» кушымтасының хәбәрчесе булды. Алсу илһамланып иҗат итә. Казан кызга канатлар куеп кайтарды! Туган татар телебез безнең мәктәптә хәзер бик югары баскычта тора. «Кирәкми, артык», – дигән фикерләрне төссезләндердек. Казанга барырга теләүчеләр бик күп, хәтта бер төркем укучыларны җәй көне алып та килдем. Өметле укучыларымның илһам канатларын ныгытырга ярдәм итсәгез, бик рәхмәтле булыр идек.*

*Хөрмәт белән, Айгөл Рәшит кызы Ахунова,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

• Гамәл һәм гадәт

# Депутат бүләге

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

21 февраль көнне Физика институтында Илдар Гыйльметдинов исемендәге стипендия тапшыру тантанасы үтте. Бу семестрда стипендиягә институт студентлары Фәнис Хәкимов һәм Гөлия Вәлиуллина лаек булды.



*Рәсемдә: Илдар Гыйльметдинов (сулдан беренче) Фәнис Хәкимов, Гөлия Вәлиуллина һәм профессор Васил Гайфуллин белән.* Алия Галимуллина фотосы

Әлеге стипендия семестрга бер, яхшы билгеләргә генә укыган, җәмәгать эшләрендә актив катнашкан, спортта уңышлары булган студентларга тапшырыла. Илдар Ирек улы Гыйльметдинов заманында физика факультетын тәмамлаган. Уку елларында иң актив студентлар сафында булуы белән беррәттән, үзен талантлы укытучы буларак та күрсәтә. Бүгенге көндә ул – РФ Дәүләт Думасы депутаты, мәгариф буенча комитет рәисе урынбасары. Һаман да студент елларын, укытучыларын сагынып искә ала. Бу стипендияне дә туган уку йортына хөрмәт йөзеннән тапшырылуын әйтте. Үзенең чыгышында депутат студентларны авыл, район мәктәпләренә чакырды, укытучының якты, уңышлы киләчәге турында ышандырып әйтә алуын белдерде. «Мәктәпләргә яхшы белем генә түгел, тәрбия дә кайтырга тиеш. Ә бу очракта инде бирердә белемле ир-атларның да эшләве кирәк», – дип искәртте Илдар әфәнде.

Факультетта инде 28 кеше әлеге стипендия иясе булган. Алар барысы да, университетны уңышлы гына тәмамлап, үз юлларын таба. Шуларның унбере – аспирант, икесе – фәнни хезмәткәр. «Мондый Дәүләт Думасы депутаты исемендәге стипендия һәркемгә бирелми. Калган студентларга да үрнәк алырга, уңышка, беренче булырга омтылырга җирлек бар», – диде Илдар Гыйльметдиновның һәм башка бик күп студентларның яраткан остазы, педагогика фәннәре докторы, профессор Васил Гайфуллин.

● Иҗат кичәсе

# «Моң колы»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

*Миңгол Галиев – моң галәме,*
*шул галәмдә*
*без комета кебек әйләнәбез.*
(Эльмира Әдиятуллина)



20 февраль көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык артисты, Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институты профессоры Миңгол Галиевнең иҗат кичәсе үтте. Чарада бәйрәмне үткәрү теләге белән чыккан Казан шәһәре мэры Илсур Метшин да катнашты.



*ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев тәбрикли*



*Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары Ренат Вәлиуллин һәм ТР Композиторлар берлеге рәисе Рәшид Кәлимуллин котлый*

Миңгол Галиев дигән шәхес турында ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. 1941 елның җәендә бишенче бала булып дөньяга килгән сабыйны язмыш беренче көннәрдән үк зур сынаулар алдына куя. Алар гаиләсенә сугыш зур кайгы алып килә. Әтиләре сугыш кырларында хәбәрсез югала. Балачак елларының ничек авыр икәнен, балаларны аякка бастыру өчен, әниләренең ничек тырышканын Миңгол абый үзе генә беләдер.

Аңа Аллаһы Тәгалә чиксез талант биргән. Беренче тапкыр зур сәхнәгә мәктәп елларында аяк баскан яшь җырчы бүгенге көндә инде Татарстанда гына түгел, ә бөтен дөньяга сибелеп яшәүче милләттәшләребезнең яраткан җырчысы. «Минем моңым – әнием моңының бер тамчысы», – дип әйтергә ярата ул. Ләкин шул бер тамчы моңны да ул мәңге сулмас чишмә тавышы кебек халкына тапшыра белә. Алай гына түгел, көченнән килсә, Мөгаллим бөтен җир шарындагы кешене җырларга өйрәтер иде.

Кичәдә яңгыраган теләкләр, аның белән бәйле истәлекләр, катнашучылар, залга җыелган тамашачы Миңгол абыйның ни дәрәҗәдә нечкә күңелле, игътибарлы, олысын да, кечесен дә якын күреп, һәркемгә ярдәм итәргә ашыгуын тагын бер кат дәлилләде. Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатын тапшыру өчен, сәхнәгә менгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Президиум әгъзасы, Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев: «Миңгол исемен мин «моң колы» дип аңлатыр идем. Сезнең җырлаганны ишеткәч, татар моңы шундый булырга тиеш, дип уйладым. Безнең хөрмәтле җырчыларыбыз бик күп, ләкин сезнең моң дәрьясында үз урыныгыз бар», – диде.

Мөгаллим өчен иң зур дәрәҗә – укучыларының уңышлары. Өч дистәдән артык гомерен яшь буынга музыка сәнгатен өйрәтүгә, җыр-моңга мәхәббәт тәрбияләүгә багышлый ул. Бүген Миңгол абыйга 7 яшьтән башлап 70 кә кадәр яшьтәге кешеләр йөри. Укытучының җырларга өйрәтү методикасын кабул итмәгән галимнәр дә булды, ләкин анда шөгыльләнгәннәрнең барысы да танылган җырчы булмаса да, һәркайсының күңелендә җырчы сандугач яши. Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, юбилярны котлап, ректорыбыз Илшат Гафуров исеменнән Рәхмәт хаты тапшырды. «Миңгол Вәгыйз улы – безнең уку йортының иң әзерлекле, иң тәҗрибәле, иң гадел укытучыларының берсе. Ул әзерләгән студентлар, җырчылар – чын сыйфат билгесенә ия белгечләр. Алга таба да безгә бергә эшләргә язсын», – диде.

Остазны студентлары ничек хөрмәт итсә, ул да аларны шулай ярата, аның күңелендә һәркайсының үз урыны бар. Эшенең нәтиҗәсе халык күз алдында. Сәхнә түренә чыккан укучылары чыгыш ясаганда да Миңгол абый алар янәшәсендә булды. Фердинанд Сәлахов, Рөстәм Закиров, Ләйсән Гыймаева, Закир Шаһбан кебек танылган җырчылар эстрада күгендә якты йолдыз булып балкыйлар. Галимнең халык җәүһәрләрен мәңгеләштерү өчен тырышуы, аны яшь буынга тапшыруы шулай ук зур хөрмәткә лаек. Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Айдар Галимов җыр башкарыр алдыннан: «Миңгол абый хәтта ял иткәндә дә эшли. Башкортстанда ял йортында ятканда да, андагы кешеләрне җырларга өйрәтте. Сезне алар тагын чакыралар», – диде.

Юбилярны котлап, бик күп рәхмәт хатлары, бүләкләр, чәчәк бәйләмнәре тапшырылды. Ләкин җырчы һәм мөгаллим өчен иң зур бүләк ул – тамашачы, халык мәхәббәте. Ил яшәве – моң белән, диләр. Бу кичәдә, Миңгол абыйдай шәхесләребез, аның укучылары кебек дәвамчылар булганда, татар моңы яшәячәгенә тагын бер кат инандык.

● Дөнья үзебезнеке

# Кайда танышасыз?



**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Һәртөрле мәхәббәт
үзенә күрә матур һәм дөрес,
әмма ул башта түгел,
йөрәктә булырга тиеш...

*— Егетемә Гашыйклар көненә нәрсә алырга икән?..*
*— Белмим инде... Күпме очрашуыгызга карап...*
*— Күпме дип, озак түгел инде...*
*— Кайда таныштыгыз соң?*
*— ...Интернет челтәрендә...*

*Бу әңгәмәне бүген автобуста кайтканда ишетергә туры килде. Билгеле, рус телендә иде ул. Кызык булып китте: дөрестән дә, кайда таныша соң бүгенге яшьләр? Вакытлар үзгәргән саен, һәр өлкә техникалашкан кебек, мәхәббәт өлкәсенә дә әкренләп «виртуальләшү» дигән төшенчә кереп бара. Әти-әниләребез танышкан театр-концерт, аулак өйләргә алмашка төрледән-төрле Интернет порталлары, танышу сайтлары килә. Бер уйлап карасаң, җайлы бит: урамга чыгасы юк, кирәкле параметрларны керттең һәм, вәссәлам, бер генә түгел, ә йөзләгән кешене чыгарып бирә! Урамга чыгып, уңга-сулга карап йөрергә дә туры килми.*



*Сайтларның күбесе, әлбәттә, рус телендә, ләкин әле бер-ике ел элек кенә татарлар өчен махсус tatarlove.ru исемлесе ачылган. Яшьләр арасында бу сайт инде популяр санала. Шулай ук танышу өчен бик кулай булган «Вконтакте» челтәре дә үзенең актуальлеген югалтмый. Төрле шәһәрләрдән үзеңә кирәклесен табарга мөмкин! Иң мөһиме, челтәрнең «теге башында» булган кешеңә ошарга гына кирәк! Әле бер-ике ел элек кенә Интернетта таныштым дип хәтта әйтергә оялып йөрүчеләр булса, бүген бу җавап берәүне дә гаҗәпләндерми. Онытып торам икән: радиоларда да яшьләргә танышу өчен кич белән махсус мөмкинлекләр бирелә! Мәсәлән, бездә һәрдаим сөйләп торган «Татар радиосы»нда нинди генә эчтәлекле танышу хәбәрләре ишетергә туры килми! Тугрылыклы мәхәббәтен эзләүчеләр дә, бер көнгә күңел ачарга чакыручылар да, хәтта, сөйгәне башка җиргә киткәнгә, икенче берәүне кунакка чакырып ятучылары да очрый.*

*Әлбәттә, минем һич кенә дә бары тик урамда яки күзгә-күз очрашканнан соң гына таныша башларга кирәк, дигән фикер белдерәсем килми. Бары тик чамасын белергә, виртуаль дөньядагы меңләгән кешегә кызыкканчы, үз тирәңдә әллә кайчаннан сине күзләп, йөрәге белән чын-чынлап яратып йөрүчеләрне дә онытмаска кирәктер... Күктәге торнага караганда, кулыңдагы чыпчык яхшырак, диләрме әле?!*

● Ватанны саклаучылар көне 23 февраль

# Безнең арада ул батырлар!

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Казан федераль университеты галимнәре арасында да нинди генә язмышлы кешеләр юк! Галим һәм шәхес...



Бүген сүзебез КФУ ның Тарих институтыннан тарих фәннәре докторы, профессор Альберт Борһанов турында. Идел-Урал, Урта Азия һәм Урта Көнчыгыш төбәкләренең борынгы, урта гасырлар тарихына һәм археологиясенә багышланган 400 дән артык фәнни эшләр авторы, күренекле тарихчы-археолог һәм Көнчыгыш илләре белгече студентларына шул илләрнең тарихы турында лекцияләр укый. Ул Иран, Урта Азия, Әфганстан илләре турында сөйләгәндә, шәкертләре укытучыларын тын да алмый тыңлыйлар. Нигә дисезме? Альберт Әхмәтҗан улы бу җирләрдә үзе дә булган, яшәгән, хәтта сугышта катнашкан...

Чиләбе дәүләт педагогия институтын тәмамлап, Төркмән Фәннәр академиясенең Ш.Батыров исемендәге Тарих институтының археология бүлегендә эшли башлаган яшь галимне армия сафларына чакырып, повестка килә. 1979 елның салкын декабрь аенда 23 яшьлек рядовой-срочник Альберт Борһанов автомобиль частьләре составында Әфган җиренә аяк баса. Гасырлар буе үзенең язылмаган законнары, тормыш итү тәртибе белән яшәгән, күп төрле этник, дини, сәяси һәм башка каршылыклардан телгәләнгән, сугыш төтененә уралган тау иле була ул. Хәрби йөкләр ташучы, яңа юллар төзүче булып хезмәт иткән Борһановка һәм аның иптәшләренә, күп мәртәбәләр үлем белән күзгә-күз очрашып, ирексез сугышларга керергә, якын дусларын югалтырга һәм һәлак булганнарны цинк табутларда соңгы юлга – туган илгә озатулар... – барысын да башкарырга, күрергә туры килә.

Альберт әфәнде Әфганда булган бу тетрәндергеч хәлләрне сөйләргә яратмый. Үзегенә үткән, дүрт елга сузылган коточкыч афәт хәрби-интернационалист күңелендә гомерлеккә уелган. Һәр елның 15 февралендә – Совет гаскәрләренең Әфган җиреннән чыгарылган көнендә - исән калган сугышчы дуслары белән очрашканда, ул Көньяк кояшыннан төсе уңган, тимгелле, куе рәтләр булып сугыш бүләкләре тезелгән комуфляж формасын – «афганка»сын кия.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла